# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

№1 02.11.2022

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге Мортыш Баш авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә ТР Законының 2 ноябрендә «2023 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Илексаз авыл җирлеге Мортыш Баш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300,00 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә риза буласызмы?" мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде, моннан тыш, вакытлы хәрби хезмәт узучы, Украина территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларыннан, 1 Төркем инвалидларыннан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә тотарга Сез ризамы:

1) Мортыш Баш авылында авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш җәелгән чокырлар ремонты, вак таш ташу);
2) Мортыш Баш авылында "Беларус 82.1" тракторын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, һәм машина йөртүче хезмәте өчен түләү);
3) Мортыш Баш авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (материаллар алу);
4) Мортыш Баш авылы зиратына инвентарь, техника өчен запас частьлар сатып алу;
5) янгын куркынычсызлыгы өчен җиһазлар (мотопомпалар өчен запас частьләр) сатып алу;
6) Мортыш Баш авылы эчендәге юлларны кардан чистарту;
7) Мортыш Баш авылында массакүләм чаралар (Сабантуй, юбилярлар, Җиңү көне, Өлкәннәр көне, Яңа ел) үткәрү өчен бүләкләр алу.

«ӘЙЕ ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 189 катнашучы кертелгән, җыенда катнашучылар саны 107 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 102 кеше тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 5 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлегендә узган халык җыенын халык җыены нәтиҗәләре – чын мәгънәсендә, дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Илексаз авыл җирлеге Мортыш Баш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән вакытлы хәрби хезмәт узучы, Украина территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларыннан, 1 Төркем инвалидларыннан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, 2023 елда үзара салым кертергә риза:

1) Мортыш Баш авылында авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш җәелгән чокырлар ремонты, вак таш ташу);
2) Мортыш Баш авылында "Беларус 82.1" тракторын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, һәм машина йөртүче хезмәте өчен түләү);
3) Мортыш Баш авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (материаллар алу);
4) Мортыш Баш авылы зиратына инвентарь, техника өчен запас частьлар сатып алу;
5) янгын куркынычсызлыгы өчен җиһазлар (мотопомпалар өчен запас частьләр) сатып алу;
6) Мортыш Баш авылы эчендәге юлларны кардан чистарту;
7) Мортыш Баш авылында массакүләм чаралар (Сабантуй, юбилярлар, Җиңү көне, Өлкәннәр көне, Яңа ел) үткәрү өчен бүләкләр алу.

3. Әлеге карарны кабул ителгән көннән 7 көн эчендә Илексаз авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында, http://sarmanovo.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга .

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Илексаз авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Сарман муниципаль районы
Илексаз авыл җирлеге башлыгы Гыйлфанов Ф.М.